**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 16 декабрендәге 4457 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 октябрендәге 3420 номерлы «Казан шәһәренең Вахитов районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Техник хаталар җибәрелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 октябрендәге 3420 номерлы «Казан шәһәренең Вахитов районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктчада «29 кв.м» сүзләрен «23 кв.м» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.3. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 октябрендәге 3420 номерлы карарына 2 номерлы кушымта дип санарга.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**